**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 февраль № 114

г. Казань

Эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү, эшчеләрне кабат әзерләү программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүне оештыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Озак вакытлы дәүләт икътисад сәясәте турында» 2012 ел, 7 май, 596 нчы, «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 597 нче, «Мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 599 нчы указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә һәм икътисад өлкәсен квалификацияле эшче кадрлар белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү, эшчеләрне кабат әзерләү программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүне оештыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына 2015 елның 1 маена кадәр эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү, эшчеләрне кабат әзерләү программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын тормышка ашыру өчен белем бирү оешмаларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, ел саен, укырга кабул итү буенча контроль саннар билгеләнә торган ел

алдыннан килгән елның 20 июленә кадәр, Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә туры килүче сорала торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеген исәпкә алып һәм эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү, эшчеләрне кабат әзерләү программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказы нигезендә эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү, эшчеләрне кабат әзерләү программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүгә финанс чыгымнары нормативларын раслау турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\114.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 февраль, 114 нче
карарына кушымта

**Эшче һөнәрләре, эшчеләрне кабат әзерләү буенча һөнәри әзерлек программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүне оештыру тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. эшче һөнәрләре, эшчеләрне кабат әзерләү буенча һөнәри әзерлек программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүне оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип)   конкурсын (алга таба – конкурс)

.

1.2. Конкурсны оештыручы булып Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тора.

1.3. Конкурсны үткәрү максаты - эшче һөнәрләре, эшчеләрне кабат әзерләү буенча һөнәри әзерлек программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын (алга таба – дәүләт заказы) гамәлгә ашыру өчен белем бирү оешмаларын сайлап алу һәм Татарстан Республикасы предприятиеләрен квалификацияиле эшче кадрлар белән тәэмин итү.

1.4. Кабул итүнең контроль саннары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнгән кысаларда Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларына куела.

## 2. Кадрларны тизләтеп әзерләүгә төп таләпләр

2.1.  эшче һөнәрләре, эшчеләрне кабат әзерләү буенча һөнәри әзерлек программалары буенча кадрларны тизләтеп әзерләү (алга таба – кадрларны тизләтеп әзерләү) Татарстан Республикасы тармак министрлыклары карамагында булган белем бирү оешмаларында гамәлгә ашырылырга мөмкин, оештыру-хокук рәвешенә карамастан, лицензиясе булган, белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокук бирелгән белем бирү оешмасына

2.2. Конкурска тәкъдим ителә торган тизләтелгән әзерлек программалары түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

Татарстан Республикасы икътисадын модернизацияләүнең төп өстенлекләрен һәм һөнәри стандартлар таләпләрен һәм юнәлешле заказчыларны исәпкә алып .....эшче һөнәрләрен тәкъдим итүгә ориентацияне;

дистанцион белем бирү технологияләреннән файдаланып укытуны гамәлгә ашыру мөмкинлеген;

белем бирү оешмалары яки Татарстан Республикасы предприятиеләре (оешмалары) базасында практик эшне оештыру өчен укыту кимендә 50 процент вакытын файдалану;

практик эшне тормышка ашыру өчен заманча матди-техник база, шулай ук тиешле квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр булу;

бу Тәртипнең 2.6 нчы пункты нигезендә тизләтелгән әзерлек программасын үзләштерүне аттестация белән тәмамлау.

2.3. Кадрларны тизләтеп әзерләү укуның көндезге һәм көндезге-читтән торып уку формалары буенча гамәлгә ашырыла;

2.4. Кадрларны тизләтеп әзерләү бер елдан артмаска тиеш (җитештерү практикасы уку планы өлеше булганда, җитештерү практикасы вакытын исәпләп).

2.5. Кадрларны тизләтеп әзерләүне үткән чорда тыңлаучыларга стипендия түләтми.

2.6. Кадрларны тизләтеп әзерләү белем бирү оешмалары билгеләгән тәртиптә үткәрелә торган өйрәнүне тәмамлаган затларны аттестацияләү белән тәмамлана.

2.7. Өйрәнүне тулы күләмдә үткән һәм өйрәнүдән соң аттестация үткән затларга белем бирү оешмалары тарафыннан билгеләнгән үрнәктә документлар бирелә.

## 3. Конкурс сайлап алуне үткәрү шартлары һәм катнашучыларга таләпләр

3.1. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – тармак министрлыклары) ел саен:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында .......

территориаль киселештә .......... кабул итү контроль саннары күләме;

гаризаларны бирә башлау датасы һәм урыны;

гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы һәм вакыты;

Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү датасы.

3.2. Конкурсны үткәрү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән оештырыла торган конкурс комиссиясе тарафыннан белем бирү оешмалары биргән гаризалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Белем бирү оешмалары планлаштырыла торган ел алдыннан килүче елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Конкурс комиссиясе турында нигезләмәдә күрсәтелгән форма һәм таләпләр нигезендә гариза бирәләр.

3.4.

3.5.

3.6. Конкурс комиссиясе планлаштырыла торган ел алдыннан килүче елның 1 ноябренә кадәр

3.7. Тармак министрлыклары планлаштырыла торган ел алдыннан килүче елның 10 ноябренә кадәр

3.8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган Конкурс комиссиясе турында нигезләмә белән билгеләнә.

3.9.

3.10.

3.11. Тармакара профессияләр буенча кабул итүнең контроль саннары Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана һәм ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларының дәүләт бурычларына кертелә.

3.12. Конкурс комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган форма буенча

---